Чыганак: **Мәдәни җомга.- 2012.- 22 июнь**

# 2012 – Кәрим Тинчурин елы да

Быел 15 сентябрьдә халкыбызның мәшһүр драматургы һәм артисты, татар театрына нигез салучыларның берсе Кәрим Тинчуринның тууына 125 ел тула. Бу бөек шәхеснең юбилеен зурлап билгеләп үтү буенча берникадәр өзерлек эшләре башланды инде. Шул уңайдан К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында бертөркем галимнәр, артистлар, театр һәм фән эшлеклеләре очрашып сөйләште. Мәсәлән, көз көне К.Тинчурин театрында әлеге күренекле датага багышлап, татар театрларының фестивале үткәреләчәк. Дөрес, оештыручыларның сүзләренә караганда, бу фестивальдә К.Тинчурин әсәрләрен уйнау төп шарт итеп куелмый. Аннан соң Казанның Кәрим Тинчурин урамындагы паркка драматургның бюсты куелачак. К.Тинчурин исемендәге театрда исә әдипнең шәхси әйберләреннән күргәзмә әзерләнә. Әмма шулай да драматургның мирасы музей булдыруны сорый.

К.Тинчуринның хәләл җефете Заһидә апа озак еллар дәвамында иренең шәхси әйберләрен, аның дөнья күрмәгән әсәрләрен, гаилә мирасын күз карасыдай саклап килгән.

“Кәрим Тинчурин бик мавыгучан, төрле коллекцияләр җыярга хирыс кеше булган, – дип сөйләде Татарстанның халык язучысы Рабит Батулла. - Әйтик, аның Алманиядә эшләнгән югары сыйфатлы 8 фотоаппараты булганлыгы мәгълүм. Аның төшергән фотоларыннан үзе бер фотокүргәзмә ясарлык. Әдипнең фотоархивы миндә саклана. Аннан соң ул Терегулов белән ярыша-ярыша антиквар әйберләр җыя. Зәвекъле кытай чынаяклары, йорт җиһазлары... Ә инде бүләкләрнең исәбе-хисабы булмый. Мәсәлән, Идел буе хәрби округыннан бүләк итеп бирелгән исемле Венчестер автоматы, Габдулла Кариев бүләк иткән алтын сәгать. Гомумән, андый бүләкләр йөзләп исәпләнә. 1937 елны, К.Тинчуринны кулга алган вакытта, аның күп әйберсен үзләштерәләр. Аңа, советларга каршы булган, дип, яла ягу күз буяу гына, билгеле. Әдипнең алтыннарын, кыйммәтле әйберләрен талап алып, зур фатирына кереп утырасылары килгән. Советлар хөкүмәте Заһидә Тинчуринага 70 яшенә җитеп килгәндә генә бер бүлмәле фатир бирә. Әле анда да кышларын җылылык 14 градустан югары күтәрелми иде. Аңа кадәр Заһидә апага кайларда гына яшәргә туры килми. Бөек Ватан сугышы вакытында, шпионлык итеп йөрер, дип, шикләнеп, аны Чуашстандагы бер авылга сөрәләр.

Заһидә Тинчурина нинди авыр вакытларда да иренең архивын саклап кала. Ачлыктан интеккәндә үз әйберләрен сата, Тинчуринныкына кагылмый. Заһидә апа 5 ел “Сәйяр”дә эшләгән, драматик рольләрне оста башкаручы бик көчле актриса була. Статский киңәшче Шаһбазгәрәй кызы ул. Дворянка. Мәгънәсез, рәхимсез заманны кичергән каһарман кеше. Ул гомер буе башта авиация техникумында, аннан соң педагогика институтында татар теле һәм әдәбияте укытты. Аның турында мин 10 ел чамасы элек пьеса язган идем. Әмма аңа бер театр да алынмады. Нәфис фильм төшерсәң дә, әйбәт булыр иде. Гомумән, ул заман шәхесләренең һәрберсе турында тулы метражлы нәфис фильм төшерерлек. Материаллар бар.

Заһидә апа Тинчурина иренең бөтен әйберләрен, архивын К.Тинчурин исемендәге драма һәм комедия театрына васыять итеп калдырды. Ул документлаштырылган. Шуңа күрә бу театрда музей тиешле дәрәҗәдә оештырылырга тиеш. Анда әдипнең бөтен тормышын белүче бер экскурсовод та билгеләп куярга кирәк”.

Рабит Батулла Казанда К.Тинчурин һәм С.Сәйдәшев исемендәге музыкаль драма һәм комедия театры ачарга да тәкъдим итте. “Бу театр өчен бер төркем талантлы яшьләрне ГИТИСка укырга җибәрергә кирәк, - диде ул. – Сәйдәшев һәм Тинчуринның иҗади дуслыгы нәтиҗәсендә “Зәңгәр шәл”, “Кандыр буе” һәм башка гаҗәеп музыкаль драмалар дөньяга килгән. Гомумән, Салих Сәйдәшевнең композитор булып китүендә Кәрим Тинчуринның роле гаять зур. Аларның иҗаты да аерылгысыз”.

Әдәбият галиме Фоат Галимуллин Кәрим Тинчуринның кулга алыну вакыйгасын кабат хәтердә яңартты. “20 нче елларда иҗат кешеләре артыннан шымчылык бик көчле булган, - диде ул. – ОГПУ органнары күзәтеп, К.Тинчуринның Г.Исхакый белән элемтәдә торуын белеп, андый кеше театрда эшләргә тиеш түгел, дип нәтиҗә ясый. 1928 елда К.Тинчуринның Әстерхан театрына китүе юктан гына түгел. Әмма аны чынлап торып гаепләргә сәбәп табылмый. 1937 елда драматургка совет дәүләтенең 20 еллыгына багышлап пьеса язарга дәүләт заказы бирелә. К.Тинчурин “Шомырт чәчәк атканда” дип аталган пьеса яза. Партия өлкә комитетында бу әсәрне уку оештырыла. Анда Кави Нәҗми, Ширияздан Сарымсаков, Риза Ишморатларның булуы мәгълүм. Әсәрне бик хуплап кабул итәләр. Шунда сүз иярә сүз чыгып берәү әйтеп куя: “Бер укытучыга Төркиядән пакет килгән. Бүгенге көндә мондый хәлнең булуы мөмкинме?” – ди. Шунда Кәрим Тинчурин аны-моны уйламастан, әйтеп ташлый: “Ә нигә мөмкин булмасын, - ди. – Минем үземә күптән түгел Төркиянең “Милли юл” журналыннан хат килде”. Шуннан соң өлкә комитетыннан Яушев фамилияле берәү “Әсәрнең язмышы турында алга таба сөйләшербез”, - дип, җыелышны яба.



Кәрим Тинчурин. 1937 ел.

Ул елны К.Тинчуринның 50 яшьлеген театрда зурлап билгеләп үтәләр. Төрки республикалардан да кунаклар килә. Республика җитәкчеләре дә катнаша бу бәйрәмдә. Төн уртасы узгач, бик күп бүләкләрне күтәреп кайтып китәләр. Таң ата башлагач, ишек шакыйлар. Әдипкә кичә генә бирелгән бүләкләрне, өендәге кыйммәтле әйберләрне талыйлар, үзен алып китәләр. К.Тинчуринның кулга алынуы бик тә фаҗигале була.

Моңарчы без аны 1948 елда һәлак булган, дип әйтә килдек. Бары тик К.Тинчуринның 100 еллыгын үткәргәндә Татарстан Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары, профессор Мансур Хәсәнов Кәрим Тинчуринның 1938 елда, 15 ноябрьгә каршы төндә атып үтерелүе турында хәбәр итте. Залда Заһидә апа да утыра иде. Шунда халык дәррәү килеп, аны сәхнәгә, президиумга менгереп утыртуларын таләп итте. Заһидә апаны ике яктан күтәреп, ямьсез рәвештә сәхнәгә алып менүләре әле дә күңелемне тырнап, күз алдымнан китми тора. Югыйсә, алдан, матур итеп чәчләрен тарап президиумга утыртып куйсалар, ак сакаллы карт буласы иделәр бит.

Гомумән, К.Тинчурин искиткеч зур шәхес. Быел аның юбилеен тиешле дәрәҗәдә үткәрергә насыйп булсын иде”.

**Чулпан ФӘРХЕТДИНОВА.**